**Исәнбай халкы хезмәт фронтында**

Бөек Ватан сугышы башлангач, авылдагы (колхозда) төп эшче куллар Ватан сугышына һәм хезмәт армиясе сафларына мобилизацияләнделәр, шуның өчен машиналар һәм атлар белән эшләү хатын-кызлар кулына күчте. Шулай итеп, колхозда төп эшче көчләр булып хатын-кызлар, яшь-үсмерләр, карт-корылар калды.

Хатын-кызлар колхозда җитәкче, гади һәм авыр эшләрне эшләүчеләр, шулай ук машиналарны эшләтүчеләр булып калдылар. Гөбәйдуллина Нәҗия, Ягъфарова Фәхимә (Рәхимә), Вахитова Баһира, Фәйзуллина Хәҗәр, Симакова Мәхмүдә, Ахмадуллина Җәмилә, Борһаниева Рәхимә, Тукманова Камиләләр бригадир булып эшләделәр. Тукманова Минҗан ферма мөдире булып эшләде. Егерме бер хатын-кыз механизаторлык һөнәрен үзләштереп, тракторист, комбайнер һәм аларның ярдәмчеләре булып эшләделәр. Шулардан Галимуллина Зәйтүнә, Ахунҗанова Галия, Баһаутдинова Маһироза, Хакимова Зөбәрҗәт, Мухъянова Фәүзия, Халикова Кәшифә, Ахмадуллина Факыя, Борһаниева Нәгыймә, Сәйфетдинова Габидә, Мөсифуллина Мөкәрәмә, Фәтхетдинова Мөгалимә, Нәҗметдинова Нурҗиһан, Маннанова Миңнур, Саликова Мәрхәбә, Аскарова Нажия - тракторчылар, ә Сундукова Зөһрә, Вагапова Һәдия, Ахунҗанова Нәгыймәләр комбайнер ярдәмчеләре булып эшләделәр. Бу вакытта механизатор булып эшләү авырга туры килә иде. Яңа машиналар кайтмады, иске машиналар бик йончыган иде, машиналар туктаусыз ремонтлап эшләнде. Ремонтлау өчен запас частьләр юк иде. Запас частьләрне тимер юл станцияләреннән, сугышта җимерелеп кайткан танк, трактор һәм автомобильләрдән генә сүтеп алалар иде. Шулай булуга карамастан, хатын-кызлар машиналарда эшләү буенча зур оешканлык күрсәттеләр. Аларның күбесе хезмәт фронтындагы активлыклары өчен почет грамоталары, медаль һәм орденнар белән бүләкләнделәр. Шулар арасыннан МТСта эшләгән Исәнбай кызы Ваһапова Һәдия “Хезмәт Кызыл байрагы ордены” белән бүләкләнде.

Сугышка кадәр ат белән эшләү түгел, атның дилбегәсен дә тотып карамаган хатын-кызлар икешәр ат җигеп эшкә тотындылар. Безнең колхозда барлыгы 60ка якын хатын-кыз ат белән эшләде. Алар колхозда атлы эш башкару белән генә тукталып калмадылар, фронт заказларын үтәүдә дә актив катнаштылар. Су һәм тимер юл транспорты өчен утын кистеләр, ташыдылар, вагоннарга төяделәр. Бондюг заводында эшләгән әйберләрне ат белән Казанга алып бардылар һәм аннан шулай ук завод һәм МТС өчен кирәкле әйберләр алып кайттылар. Сугыш елларында ат белән иң яхшы эшләүче хатын кызларыбыз: Даутова Мөнәзәһә,Зәйнетдинова Хәҗәр, Баһаветдинова Хәтимә, Тютеева Мөнирә, Фәйзуллина Гөлҗәүһәр, Ямалиева Сәхип, Ибәтуллина Газзә һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин. Даутова Мөнәзәһә, Мөфтиева Камилә сугыш елларында ирләр эшли торган эшләрне башкардылар. Алар атлар карауӵы да ат белән эшләүче дә почта ташучы да ат белән Бондюг заводында эшләнгән әйберләрне Казанга, Казаннан Бондюгка материаллар ташучы да була. Ә 1943 нче елда бер ел тимер юл транспорты өчен утын кисү, вагоннарга төяү эшендә бик яхшы эшләгәннәре өчен алар 1943 нче елның 5 август указы белән ТАССР Верховный советы призидиумы тарафыннан почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

Колхоз транспортының төп көче булган атларны тәрбияләргә күп кенә хатын-кызлар ат караучылар (конюхлар) булып эшләделәр. Шулардан Зарипова Гайникамал, Калимуллина Бибинур, Даутова Әминә, Вахитова Хәдичә, Сундукова Кәүсәрия һәм башкалар тырыш хезмәт үрнәкләре күрсәттеләр.

Хатын-кызлар урып-җыю, дәүләткә икмәк тапшыру эшләрендә дә зур активлык күрсәттеләр. Мәсәлән, түбәндәге хәлне язып үтү дә моның бик ачык мисалы булып тора. 1942 нче елның ноябрь башларында (ул елны салкыннар иртә башланган иде) җирләр 20 нче октябрьгә үк нык туңган иде. Фрунзе исемендәге колхоз әгъзәләре Октябрь бәйрәме көненә дәүләткә икмәк тапшыру планын үтәү өчен көрәшәләр. Дәүләткә тапшырырлык киптерелгән икмәк җитештермәгәнлектән, партия оешмасы ашыгыч рәвештә икмәк киптерүне оештыру турында күрсәтмә бирде. Шуның нигезендә һәр колхозчы хатын-кыз һәм авылның башка хезмәткәрләре көндезге эштән соң, кич белән икмәк киптерү өчен сушилка төзү эшенә тартылды. Лумнар, балталар, көрәкләр белән коралланган хатын-кызлар сугышка буласы урындагы туң җирне чабып, казып төннәр буена сушилка төзү эшендә эшлиләр һәм аларның үзләрен аямыйча тырышып эшләүләре нәтиҗәсендә, сушилка кыска гына вакыт эчендә дә бетә.

Хатын-кызларны бу ашыгыч эшне эшләүгә туплауда шул вакытта авылның китапханәчәсе булып эшләүче Ризванова Һава апаның тырышлыгы зур йогынты ясады. Бу төзелгән сушилкада атналар буена туктаусыз эш кайнады, дәүләткә тапшыру өчен икмәк киптерелде. Октябрь бәйрәме якынлашкан көннәрдә дәүләткә икмәк тапшыру буенча өмәләр үткәрелде, шул өмәләрнең берсендә 160 арба берьюлы Каракүл заготзерносына икмәк белән озатылды. Бу өмәләрдә колхозчы хатын-кызлар белән бергә авылның башка хезмәт ияләре дә тырышып эшләделәр һәм шуның нәтиҗәсе буларак дәүләткә ашлык сату планы вакытыннан алда, арттырып үтәлде.

Авылда хатын-кызлар авыл хуҗалыгы эшләрен башкару, дәүләткә авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү белән бергә сугышчыларга җылы киемнәр хәзерләп җибәрүдә дә тырышлык күрсәттеләр. Күп күләмдә җылы кием тегү өчен сарык тиресе, җылы оеклар, бияләйләр, бүрекләр, шарфлар җыйдылар һәм үзләре хәзерләделәр, бәйләделәр. Бу эштә Ризванова Һава, Гыймаева Роза, Ситдикова Һәҗия, Мөсифуллина Мәрьям, Галиева Зәйтүнә, Җәмилева Зәкия, Борисова Кәүсәрия һ.б. хатын-кызларыбыз зур активлык күрсәттеләр.

Колхозчылар һәм авыл кешеләре фронтка ярдәм итү белән беррәттән фронтовик семьяларын да онытмадылар. Аларның тиешенчә мәктәпкә йөрүен тәэмин итү өчен, авыл активы 1944 нче елда гына да түбәндәге күләмдә кием хәзерләп бирде. Киез итек – 40 пар, күлмәк – 20, чувяк – 12 , тире – 33 баш, йон – 6 кг, төрле кием – 24 данә, бәрәңге – 667 кг, акча – 900 сум. Шулай ук үз хуҗалыкларына дәүләттән заем сатып алып, аның взносларын әз вакыт эчендә җыеп тапшырдылар, хәтта башка хезмәт ияләренә мөрәҗәгать язып, район газетасында игълан иттеләр. Самолетлар, танклар төзүгә акча туплауда актив катнаштылар . Бәйрәмнәр алдыннан сугышчыларга бүләкләр хәзерләп җибәрделәр. Моның өчен Ватан сугышы фронты гаскәрләреннән авыл хезмәт ияләренә рәхмәт хатлары килде. Менә шуларның берсе Калинин фронтыннан редакциягә язылган хат:

*“Иптәш редактор! Газетагызда түбәндәге хатны урнаштыруыгызны сорыйбыз.*

*Кадерле иптәшләр – Исәнбай авылының колхозчылары һәм колхозчы хатын – кызлары!*

*Шушы көннәрдә без, Калинин фронтындагы бер авиация берләшмәсендәге НКВДның махсус бүлеге сугышчылары һәм работниклары, сездән, Исәнбай авылы колхозчыларыннан бүләк посылкасы алдык.*

*Бүләк өчен, безгә, фронтовикларга күрсәтә торган кайгыртучанлыгыгыз өчен, сезгә, кадерле колхозчылар, чын күңелдән рәхмәт белдерәбез.*

*Безнең социалистик илдә фронт һәм тыл бердәм, җиңелмәслек союз булып тора. Һәм бу союз, сөекле партиябез җитәкчелеге астында үзенең изге бурычын – немец фашист ерткычларны тар – мар итүне үтәп чыгар.*

*Калинин фронты гаскәрләренең фашист ерткычларны безнең изге җиребездән уңышлы рәвештә кууны дәвам иттергәнлеген сез инде газеталардан укып беләсездер. Колхозчы иптәшләр, фашист басып алучыларны бөтенләй тар – мар итү өчен тормышыбызны кызганмыйча көрәшәчәгебезгә сезне ышандырабыз. Гитлер бандитларының берсен дә калдырмыйча кырып бетерербез. Немец оккупантларына үлем!*

*Үз чиратыбызда без дә сезне Ватаныбызның көчен тагын да ныгытырга, язгы чәчүгә большевикларча хәзерләнергә һәм үткәрергә чакырабыз.*

*Без сезнең белән бергә – сез хезмәт фронтында, без сугыш фронтында фашист хәшәрәтне аяусыз кыйнарбыз һәм тар – мар итәрбез.*

*Махсус бүлек сугышчылары һәм работниклары тапшыруы буенча: Блохин, Горин, Халтурин, Куренков, Устюшин, Джигалюк, Дергунов, Кудряшёв.*

*Безнең адрес: Действующая Красная Армия. Полевая почта №1509. Особый отдел НКВД”.*

Авыл хезмәт ияләреннән бик күп кешегә Ватан сугышы елларында тырыш хезмәт күрсәткечләре өчен СССР Верховный Советы президиумы тарафыннан “1941-1945 нче еллардагы батырлык өчен” медале белән бүләкләнделәр.

Барлык авыл хезмәт ияләре белән бергә авылның укытучы хатын-кызлар коллективы да, җиңүне тәэмин итү өчен, барлык көчләрен куеп эшләделәр. Укытучылар укучыларны укыту-тәрбияләү белән бергә агитатор булып халык арасында аңлату эшләре алып бардылар, заем уполномоченныйлары булып эшләделәр, фронтовиклар өчен җылы киемнәр, бәйрәм бүләкләре җыю һәм хәзерләүне оештырдылар. Бу эштә Борисова Кәүсәрия, Җәмилева Зәкия, Гыймаева Роза, Даутова Фатыйма, Галиева Зәйтүнә, Ситдикова Һәдия иптәшләр аеруча активлык күрсәттеләр. Аерым укытучылардан Гыймаева Роза урып җыю вакытында һәр көнне 16 сотый урынына 30-35 сотый, ә Галиева Зәйтүнә 25-30 сотый кул белән иген урды. Шулай ук укытучылар игеннәрне җыю һәм сугу, дәүләткә тапшыру вакытында да актив булышлык күрсәттеләр.

Шулай итеп, безнең авыл хезмәт ияләре немец-фашист илбасарларын җиңүгә үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр. Озак көткән тынычлык килде. Менә 1945 нче елның 9 нчы мае. Бу көнне кояш көндәгедән матуррак булып чыкты. (Чөнки илгә җиңү килде, ил өстендәге сугыш сөреме таралды).

Сугыш бетү турындагы хәбәр яшен тизлеге белән бөтен дөньяга таралды. Район үзәге Красныйбордан безнең Исәнбай авылына да хәбәр иттеләр. Бөтен авыл халкы – яше-карты - барысы да авыл клубы янына митингка җыйналдылар. Ул көнне укуны туктатып, барлык укучылар да митингка алып чыгылды. Митингта катнашучылар немец-фашист илбасарларын җиңүгә илебезнең барлык көчләрен туплап совет халкының җиңүгә ирешүен оештырган өчен коммунистлар партиясенә, Совет хөкүмәтенә зур рәхмәтләрен

белдереп, сугыш вакытында йончыган колхозыбызны торгызу өчен барлык көчләрен куячакларын әйттеләр.

Укучыларыбыз укытучылар җитәкчелегендә колхозыбызга зур ярдәм итеп торды. Урып-җыйнау вакытында җиргә коелып калган башакларны, дару үләннәре, МТСка ремонт өчен кирәкле материаллар җыйнауда, җәйге кыр эшләрендә булыштылар. Алар көче белән түбәндәге эшләр эшләнде.

1941 нче елның җәйге кыр эшләрендә 185 укучы катнашып, барлыгы 3612 хезмәт көне эшләделәр. 257 кг дару үләннәре, МТС өчен 3,5 центнер чүпрәк җыеп тапшырдылар. Ә 1944 нче елның язында колхозның атларын шефка алдылар һәм 18 ат түбән көрлектән уртачага күтәрелде, кыр эшләрендә җигү өчен яраклы хәлгә китерелде. Бу язгы кыр эшләрен вакытында башкарып чыгуда һәм югары иген уңышы җыеп алуда зур роль уйнады мөрәҗәгать. Нимецлардан азат ителгән районнардагы мәктәпләрне торгызу фондына 20000 сум акча җыеп тапшырылды.

Ат белән эшләүчеләр:

1.Даутова Мөнәзәһә

2.Хафизова Миңнур

3.Зарипова Гайникамал

4.Калимуллин Бибинур

5. Бәдретдинова Мәрхәбә

6. Баһаветдинова Хәтимә

7. Тютеева Мөнирә

8. Мусина Хәдичә

9. Фәйзуллина Гөлҗәүһәр

10. Даутова Әминә

11. Тукманова Камилә

12. Ханнанова Маһинур

13. Шаймарданова Гөлҗиһан (ярдәмче бригадир)

14. Халикова Мәхмүдә

15. Ахмадишина Җәмилә (бригадир)

16. Насыйрова Зәйнәп

17. Зәйнуллина Фатыйма

18. Шәмсетдинова Мәрзия

19. Ямалеева Сәхип

20. Рашитова Наилә

21.Галиева Әсмә

22. Хамидуллина Зөләйха

23.Бәдретдинова Җәмилә

24.Тимуршина Захидә

25. Ихсанова Шәһримә

26. Ибәтуллина Шәрифә

27. Вахитова Хәдичә

28. Латыйпова Хатимә

29. Галиева Нажия

30. Хакимова Маһигөл

31. Ибәтуллина Газзә

32. Мухгалина Гөлзифа

33. Гыйльбанова Минҗан

34. Зәйнетдинова Хәҗәр

**Кызыл эзтабарлар.**

**1985 ел**